**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ДӨРЕШ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«26» ноябрь 2021 ел № 17/1

**«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августындагы вн.2/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394 һәм 397 статьялары, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 26 сентябрендәге 23/5 номерлы карарына (2017 елның 26 декабрендәге 29/2 номерлы, 2018 елның 13 сентябрендәге 23/7 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 24/1 номерлы, 2019 елның 31 октябрендәге 8/2 номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 2/1 номерлы, 2021 елның 1 апрелендәге 9/1 номерлы, 2021 елның 29 июлендәге 14/3 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка пуктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының tukay.tatarstan.ru рәсми сайтының «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм ТР, Тукай районы, Иске Дөреш авылы, Г. Тукай урамы, 21 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга),

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.М. Дусадбеков